ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Гоголя, д.1, с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Гоголь урамы, 1 йорт, Акбаш
авылы, 423958

Тел./факс: (85593) 4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 12** **« 27 » май 2021 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының
2021 елның 29 гыйнварындагы
«2021 елга Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлегендә җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә
күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын
раслау турында»гы 3 санлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗсанлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында»гы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында 196 санлы карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 17 июлендәге 10 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының «2021 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» гы 3 санлы карарына 1 һәм 2 кушымтаны әлеге карарның 1 һәм 2 кушымталары нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Акбаш авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Синагатуллина

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге
раслау турында»гы 3 санлы карарына
2021 елның "27"маенда 12 санлы
карарына 1 кушымта

2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2654,45 |
| 4. Мәрхүмнең тәнен (калдыкларын) ташу. | 754,12 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3016,41 |
| Барлыгы | 6424,98 |

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге
раслау турында»гы 3 санлы карарына
2021 елның "27"маенда 12 санлы
карарына 2 кушымта

2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Тәнне кәфенләү | 608,75 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2045,71 |
| 4. Мәрхүмнең тәнен (калдыкларын) ташу. | 754,12 |
| зират | |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3016,40 |
| Барлыгы | 6424,98 |